**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** _06.04.2018_

г. Казань

**БОЕРЫК** __323-п _

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Боровое Матюшино торак пунктында Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасын оештыру проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга 2012 елның 6 сентябрендәге ТАТ 01867 ВЭ лицензияне, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2009 елның 8 июлендәге дәүләт санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килү турында санитар-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук «ПСК XXI век» ҖЧҖ тарафыннан тапшырылган, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Боровое Матюшино торак пунктында Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасын оештыру проекты нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Боровое Матюшино торак пунктында Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасын оештыру проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасында санитар саклык зонасы чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Боровое Матюшино торак пунктында Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалыкта файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәгеләр буенча чаралар уздыруны тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Боровое Матюшино торак пунктында Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасындагы санитар саклык зонасының чикләре, су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрендәге территорияләрдән хуҗалыкта файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында

территорияләрне үстерүнең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигать ресурслары министр-
лыгының 2018 елның « 06 » апрель
№ 323-п боерыгына 1 нче
кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Боровое Матюшино торак пунктында Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләре**

Җир асты байлыклары кишәрлеге Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Боровое Матюшино торак пунктыннан 375 метр төньяк-көнчыгышка таба, урман биләмәсендә урнашкан. Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасы өч су алу скважинасыннан тора: 1Э, 2РЗ, 3-Э.

Су алу скважиналарының географик координатлары:

1Э: төньяк киңлектә – $55^0 37'32,746''$, көнчыгыш озынлыкта – $49^0 1'5,429''$;

2РЗ: төньяк киңлектә – $55^0 37'32,851''$, көнчыгыш озынлыкта – $49^0 1'6,571''$;

3-Э: төньяк киңлектә – $55^0 37'32,217''$, көнчыгыш озынлыкта – $49^0 1'6,272''$.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

Су горизонтының яхшы якланган булуын исәпкә алып, 1Э, 2РЗ, 3-Э су алу скважиналарының санитар саклык зонасындагы беренче пояс чикләре һәр скважина өчен 5х5 метр зурлыгында билгеләнә.

Санитар саклык зонасының II поясы.

1Э, 2РЗ, 3-Э су алу скважиналарының санитар саклык зонасындагы икенче пояс чикләре санитар саклык зонасындагы беренче пояс чикләренә туры килә (һәр скважина өчен 5х5 метр).

Санитар саклык зонасының III поясы.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Боровое Матюшино торак пунктында Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасындагы өченче пояс – түгәрәк рәвешендә, Куйбышев сусаклагычының яр буе линиясе белән чикләнә. Санитар саклык зонасындагы III поясның радиусы 1357 метр тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигать ресурслары министр-
лыгының 2018 елның « 06 » апрель
№ 323- п боерыгына 2 нче
кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Боровое Матюшино торак пунктында Яшьләрнең спорт-туристлык үзәгендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалыкта файдалану режимы**

1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.

# «Биосфера һәм технология» ЯАҖ

Башкаручы: Леванов Е.В.

**Боровое Матюшино торак пунктында «Яшьләр өчен спорт-туристлык үзәге»нең җир астыннан су алу җайланмасында санитар саклык зонасын оештыру проекты**

**Генераль директор________________**
**Смирнова М.Д.**

Казан шәһәре, 2009 ел.

## ЭЧТӘЛЕК


Кереш Бит

1. Геологик корылышы һәм гидрогеологик шартлар 3
2. Су алу скважиналарының геологик-техник тасвирламасы 5
3. Су алу җайланмасы урнашкан кишәрлеккә һәм су алу җайланмасының турыдан-туры янәшәсендәге җирлеккә санитар характеристика 13
4. Су алу җайланмасының санитар саклык зонасы пояслары чикләрен нигезләү 16
5. Санитар саклык зонасы территориясендә саклык чараларын үткәрү тәкъдимнәре 18


## РӘСЕМНӘР ИСЕМЛЕГЕ


1 нче рәсем.Санитар саклык зонасында 3 поясның чикләре белән вәзгыятьләр планы 4

2 нче рәсем.А-А линиясе буенча геологик-гидрогеологик кисем 6

2.1 рәсем. 13 скважинасының геологик-техник киселеше 14

2.2 рәсем. 2 РЗ скважинасының геологик-техник киселеше 15

2.3 рәсем.

3-Э скважинасының геологик-техник киселеше 15


## ТАБЛИЦАЛАР ИСЕМЛЕГЕ


2 нче табл. Файдаланыла торган һәм резерв скважиналарның төп характеристикалары 13


## КУШЫМТАЛАР ИСЕМЛЕГЕ


1. Табигать суларына химик анализ буенча № 625 беркетмә 20
2. Табигать суларына химик анализ буенча № 626 беркетмә 21
3. Табигать суларына химик анализ буенча № 5806 беркетмә 22
4. Скважиналарның урнашу схемасы һәм су алу җайланмасының санитар саклык зонасында өченче пояс чикләре 25
   Масштаб 1:25 000
5. Су алу җайланмасында санитар саклык зонасының беренче поясы планының масштабы 1:500 26
6. 1Э номерлы су алу скважинасы паспорты 27
7. 2РЗ номерлы су алу скважинасы паспорты 31
8. 3Э номерлы су алу скважинасы паспорты 35
9. Санитар-эпидемиологик бәяләмә 39
   №16.11.11.0000.Т.001357.07.09
10. 17/2-68 номерлы санитар-эпидемиологик экспертиза беркетмәсе 40
11. Гидрогеологик бәяләмә 43

# Кереш

Җир астыннан су алу җайланмаларының санитар саклык зоналарын оештыру — хуҗалык-эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган җир асты суларын пычратудан саклау буенча төп чараларның берсе.

Санитар саклык зоналарын исәпләү СанПиН 2.1.4.1110-02 нигезендә башкарылды, ул су белән тәэмин итү һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын оештыру һәм алардан файдалануга карата санитар-эпидемиологик таләпләрне билгели.

Санитар саклык зонасында режим булдыру һәм тәэмин итүнең төп максаты булып су белән тәэмин итү чыганакларын һәм суүткәргеч корылмаларын, шулай ук алар урнашкан территорияләрне санитар саклау тора.

Санитар саклык зонасы составына өч пояс керә: беренче пояс — катгый режимлы пояс, икенче һәм өченче пояслар — чикләүләре булган пояслар.

***Санитар саклык зонасының беренче поясы*** су алу җайланмалары урнашкан территорияне, барлык су үткәрү корылмаларының һәм су үткәрү каналының урнашу мәйданчыгын үз эченә ала. Ул су алу һәм су үткәрү корылмалары урнашкан урында су чыганагын очраклы яки аңлы рәвештә пычрату мөмкинлеген бетерү максатларында билгеләнә.

***Санитар саклык зонасының икенче поясы*** су үткәрә торган горизонтны микроблы пычраклардан саклау өчен билгеләнгән. Җир асты сулары агымы белән микроблы пычраткыч чыганагының су алу җайланмасына таба хәрәкәт итүнең исәпләнгән вакыты $\mathbf{T_м}$ санитар саклык зонасының икенче поясы чигеннән су алу җайланмасына кадәрге аралыкны билгеләүдә төп параметр булып тора, ул патоген организмнарның тереклек итү вакытыннан күбрәк булырга тиеш.

***Санитар саклык зонасының өченче поясы*** җир асты суларын химик пычранулардан саклау өчен билгеләнгән. Санитар саклык зонасының өченче поясы чикләре су алу җайланмасыннан файдаланы чорында җир асты суларының агымы белән химик пычрануга юл куймау шартларына карап билгеләнә. Җир астыннан су алу җайланмаларын проектлаганда, шартлы рәвештә, су катламына үтеп кергән химик матдәләр тотрыклы булып, җир асты сулары һәм токымнары белән үзара бәйләнештә булмавын кабул итәләр.

«Яшьләр өчен спорт-туристлык үзәге»нең хуҗалык-эчәр су белән тәэмин итү өчен җир асты суларын алу җайланмасы Боровое Матюшино авылыннан төньяк-көнчыгышка таба 375 метрда урнашкан (1 нче рәсем).

Геоморфологик яктан су алу җайланмасы кишәрлеге Идел елгасының сул як ярында, 55-60 метрлы абсолют билгеләрдә урнашкан.




Шартлы билгеләмәләр

проект өчен күзәтү-файдалану скважинасы

проект өчен резерв скважинасы

санитар саклык зонасының 3 нче поясындагы проект чикләре

1 нче рәсем. Санитар саклык зонасында 3 поясның чикләре белән вәзгыятьләр планы

Масштаб 1:25 000

## 1. Геологик корылышы һәм гидрогеологик шартлар

Территориянең геологик корылышының төп үзенчәлекләре аның борынгы платформа төзелеше – Идел-Урал антеклизына туры килүе белән билгеләнә, аның корылышында ике төзелеш каты бүлеп чыгарыла: аскы каты интенсив рәвештә урнашкан һәм метаморфизмлы архей катламнарыннан тора, өске каты протерозой, палеозой неоген һәм дүртенчел чорларына караган, аз күләмдә урын алган утырма катламыннан гыйбарәт.

Утырма катламы неоген һәм дүртенчел системаларның девон, карбон, пермь һәм комташ-балчыклы карбонат һәм терриген токымнары формацияләреннән тора. Хәзерге заман тектоник шартларында борынгыдан калган өслеккә бары тик өслектә урнашкан пермь, плиоцен һәм дүртенчел катламнары гына чыга. Өстенлекле рәвештә төче җир асты сулары таралыш алган зона, дүртенчел, неоген һәм Пермь катламнарын да кертеп, утырма тышлыгы кисеменең өске өлешен колачлый. Шуңа күрә әлеге проектта хәл ителә торган бурычларга карата кисемнең стратегик тасвирламасы казан ярусы катламнарының тирәнлеге белән генә чикләнә (2.1 рәсем).

**Пермь системасы**

**Урта өлеше**

**Казан ярусы**

Казан ярусы катламнары киң таралган, бары тик кипкән елга үзәнлекләренең тирән уемнарында гына юк. Алар сакмар ярусы катламнарының карстланган өслегенә сыланып ятканнар һәм кисемгә хас полифациаль циклик характерда терриген-карбонат токымнарыннан гыйбарәт.

Карала торган территориядә ярусның аскы казан өлеше кисемнең терриген-карбонат төре белән характерлана. Ул диңгез утырмаларыннан һәм диңгез култыгы фацияләреннән тора: комташ, алевролит, балчык, мергель, известьташ, гипс линзалары белән катнашкан доломит. Карбонат токымнары (известьташ, доломит, мергель) ярус өлеше кисемендәге егәрлекнең 60 проценттан артык өлешен алып тора.

Литологик-социаль составының үзгәрү характерына карап, ярус өлеше кисемендә (астан өскә таба) ныклы өч катлам бүлеп чыгаралар, алар Байтуган, Камышлы һәм Красноярск утырмалары туплану ешлыгына туры килә. Ныклы катламнарның һәркайсысы балчык, алевролит, комташ белән башланып китә һәм известьташ, доломит, мергель белән тәмамлана.

Егәрлеге 14-40 метр булган калын Камышлы утырмасы куе соры, алевритислы, куе соры известьташ, саргылт-соры доломит, сирәк кенә юка гипс катламнарыннан торган балыктан гыйбарәт.

Красноярск утырмасы, асылда, куе соры һәм яшел соры комташтан тора, кисем буенча югарыга таба известьташ һәм балчык белән алевролит катламнары булган доломит белән алышына. Ныклы катламның егәрлек – 20-35 метр. Комташлар кайвакыт егәрлеге 25 метрша кадәр булган линзалар хасил итәләр.

Аста урнашкан Казан катламнарының егәрлеге 14 метрдан 82 метрга кадәр шактый үзгәреп тора. Карала торган территориядә аскы Казан катламнарының егәрлеге – 50 метр.

Өске өлештә урнашкан Казан утырмалары Идел елгасының биек террасларын берләштереп торучы дүртенчел утырмалар таралыш алган чикләрдә көндезгә өслеккә чыга.

Ярусның өске өлешендә урнашкан Казан утырмалары диңгез кылтыгы катламнары комплексыннан тора, аларда карбонат токымнары: доломитлар, известьлы доломитлар, доломит белән катыш известьташлар өстенлек алып тора. Аскы Казан утырмаларына хас терриген катламнары биредә буйсындырылган әһәмияткә ия. Моннан тыш, өске өлештә урнашкан Казан катламнары өчен гипс белән катышу күренеше хас.

Гипс йә башка токымнарга кереп урнашкан бөртекчәләр рәвешендә очрый, яисә берничә метрга кадәр җитә торган аерым линзалар һәм катламнар булып ята. Өске өлештә урнашкан Казан ярусы астындагы утырмаларының гомуми егәрлеге 60-65 метрга кадәр җитә.

Өске өлештә урнашкан Казан катламнары, ашалган җирлектәге эзләр буенча, аскы өлештә урнашкан Казан катламнары өстендә ята. Ярус өлешенең чиге диңгез фацияләре үзгәрүгә карап, аскы Казан өлешендә урнашкан күптөрле фаунадан тора: соры һәм куе соры диңгез култыгы катламнары ята, аларга токымнарның доломит һәм гипс белән катышу дәрәҗәсе югары булуы хас, шулай ук төсләрнең тагын да ачыграк булуы, катламнарның юка урнашуы һәм еш кына фациаль үзгәреп торуы белән сыйфатлана.
Седиментация ешлыгы нигезендә дүрт калын катлам бүлеп чыгарыла:

Казан яны (14-16 метр) – ачык соры һәм соры төстә доломитка әверелә башлаган известьташлар, ачык соры һәм ак доломитлар;

Печище (8-21 метр) – куе коңгырт һәм коңгырт-көрән, гипс катламнарыннан торган соры доломитлар;

Югары Ослан (37-30 метр) – комлы-балчык катламнары, мергельләр, вак катламлы доломитлар һәм известьташлар;

Маркваши (6-14 метр) – асылда ачык соры, соры һәм яшькелт-соры төсләрендәге комлы-балчыклы мергель утырмалары.

**Плиоцен неоген системасы**

Плиоцен утырмалары карала торган территориядә киң таралыш алган, плиоцен чорына кадәрге, Иделнең һәм аның эре кушылдыклары – Казансу һәм Мишә елгаларының корыган үзәнлекләреннән формалашкан эрозия челтәрен тутырып торалар. Иделнең корыган үзәнлегенең уйсу урынында плиоцен утырмаларының егәрлеге 110-140 метрга кадәр җитә.

Борынгы плиоцен чорында формалашкан эрозия өслеге катлаулы характерда. Зеленодольск шәһәреннән алып Казан шәһәренә кадәр Идел елгасының сул як ярында корыган елга үзәнлеге киңлек юнәлешенә янәшә булып, Иделнең хәзерге үзәненә параллель рәвештә яткан. Аның текә төньяк борты өске өлештә урнашкан Пермь катламнарыннан барлыкка килгән, хәзерге төп сөзәклеккә килеп тоташа. Көньяктагы сөзәклекнең тагын да сөзәк өслеге аскы өлештә урнашкан Казан ярусының бер өлешендәге токымнардан торган, утрау рәвешендәге эрозия-корылыш калдыклары белән шактый катлаулана. Эрозия өслеге изолиниясе буенча 0 м абсолют тамгалы елга үзәнлеге 9 км алып 12 км кадәр киңлеккә ия, ә Зеленодольск һәм Васильево бистәләре арасында Куйбышев сусаклагычы үзәненә чыгу мөмкинлеге бар. Корыган елга үзәнлегенең уйсу урыны, аерым урыннарда Ассель ярусының түбәсен кисеп узып, минус 80 м абсолют тамгасына кадәр киметелгән. Корыган үзәнлекләрдәге борынгы плейстоцен чорында формалашкан плиоцен катламнарының эрозия өслеге киңлеге 0н алып 80 кадәр абсолют тамгасына үзгәрә. Корыган үзәнлекнең уйсу урынында аларның куәте 110 м га җитә.

Иделнең корыган үзәнлеге, Казансу елгасының түбән агымын кисеп үтеп, субмеридиональ һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештәге ике култыкка аерылып, үз юнәлешен үзгәртә. Елганың көньяк-көнчыгыш юнәлештәге (көнчыгыш) култыгы иң тирән эрозия кисеменә ия, аның абсолют тамгасы минус 80 м җитә, ә Мишә елгасы үзәне белән кисешкәннән соң минус 100 м кадәр җитә. Ул, күрәсең, Идел елгасының корыган үзәнлегенең төп дәвамчысы булып торадыр. Плиоцен катламнарының куәте 120 м кадәр җитә. 0 м абсолют тамгалы эрозия өслеге изолиниясе буенча корыган үзәнлекнең көнчыгыш култыгы киңлеге, Мишә елгасының корыган үзәнлеге киселешендә киңәеп һәм кабаттан киңлек юнәлешендәге һәм субмеридиональ юнәлештәге ике култыкка аерылып, 2 км алып 9 км кадәр җитә. Эрозия өслегендә беленер-беленмәс кенә чагылыш тапкан соңгысы Куйбышев сусаклагычы үзәненә кушыла. Киңлек юнәлешендәге тирән култык Идел елгасының корыган үзәнлегенең төп дәвамчысы булып тора. Плиоцен утырмаларның егәрлеге монда 180 м кадәр җитә.

Корыган үзәнлекнең (Столбище кишәрлеге), Казан шәһәренең көньяк читеннән Дәүләки, Пиголи, Никольский торак пунктлары аша сузыла торган көнбатыш субмеридиональ култыгы 0 м абсолют тамгалы эрозия өслеге изолиясе буенча 3,3 км булган уртача киңлеккә ия. Ул Дәүләки торак пункты тирәсендә 9 км кадәр киңәя һәм Столбище һәм Комлы Кавал торак пунктлары арасында 2 км га кадәр тарая.

Корыган үзәнлекнең көнбатыш култыгы киңлеге полиоцен утырмаларның таралу кырында 11 км алып 3 км кадәр үзгәрә, уйсу урын минус 60 м абсолют тамгасына кадәр җитә. Корыган үзәнлекнең уйсу урынында плиоцен утырмаларының егәрлеге 80 метрга кадәр җитә.

Карала торган территория чикләрендә плиоцен катламнарының литологик-фациаль үзенчәлекләре буенча шартлы рәвештә Соколка һәм Чистай катламнары белән чагыштырып була торган седиментацион ике ритмны бүлеп чыгарырга мөмкин, алар Акчагыл ярусына карый торган төче утырмаларның беренче куәтле калын катламы тупланган беренче этапта формалашканнар.

"Соколка катламнары" дигән атама алган борынгы Акчагыл токымнары ингрессия шартларында, агып торган сулыктан Иделдәге корыган елга үзәненең эрозияле ерганакларына тулып, формашканнар. Түбән өлештә урнашкан Акчагыл катламнарында еш кына вак таш һәм вак чуерташлы, алевритларның һәм балчыкларның сирәк катламнарыннан торган вак һәм уртача вак бөртекчәле комнар ята, соңгыларының өлеше аллювий кисемендә 5-7% артмый.

Корыган елга үзәнлегендә Соколка катламнарының аскы түшәме үзән төбендәге өлешләрне берләштереп торган линиядә 80-92 метрлы абсолют билгегә җитә. Аларның өслек түшәме плюс 10 метр – минус 15 м абсолют тамгалары арасында урнашкан.

**Дүртенчел система**

Дүртенче яшьтәге утырмалар үзәнлекнең кайбер текә сөзәк урыннарында гына булмый, эш мәйданында алар һәр җиргә таралу үзлегенә ия. Аларның егәрлеге 90 м кадәр җитә.

Тикшерелә торган территориядә дүртенчел системаның барлык төр утырмлары аерып күрсәтелә: эоплейстоцен, неоплейстоцен һәм голоцен.

Килеп чыгышы буенча дүртенчел утырмалар аллювиаль, күл-аллювиаль, элювиаль-делювиаль, эол һәм сазлык утырмаларына аерып тәкъдим ителә. Иң киң таралган аллювиаль утырмалар Казансу елгасы үзәнендәге Идел елгасының сул як ярында зур мәйданнарны биләп тора.

Эоплейстоцен утырмаларның Казан буе тирәсендә таралу мәйданы шактый.

Идел елгасы үзәннәрендә алар тугай өслегендәге бишенче террасаны тоташтыра. Бу терраса өслегенең абсолют тамагалары – 120-130 метр, киңлеге – 8-10 км.

Күбесенчә аллювиаль утырмалар буларак тәкъдим ителүче эоплейстоцен утырмалар Пермь токымына караган неоген катламнар белән түшәлә. Өслегендә алар, гадәттә, урманнардагы кебек, туфраклы балчык һәм комлы туфрактан куәтле калын (16-18 метрга кадәр) катлам белән капланган. Эоплейстоценлы утырмаларныж уртача егәрлеге 40-50 метр тәшкил итә.

Карала торган территориядә неоплейстоценның урта һәм югары өлешенә караган катламнар бүлеп бирелә. Идел елгасының урта чирекле утырмалары су астындагы дүртенче һәм өченче террасаларны барлыкка китерә.

Лихва һәм Днепр горизонтларының аллювиаль катламнары су астында дүртенче террасаны барлыкка китерә. Бөтен җирдә диярлек әлеге терраса аны су астындагы беренче яки икенче террасалардан аерып торучы төгәл киртләч белән чикләнә һәм Куйбышев сусаклагычыннан 60-85 метр биеклеккә күтәрелә. Бу терраса өслегенең абсолют тамгасы - 80-125 метр, итәгенеке 26-45 метрга тигез. Су астындагы террасаның чирек катламнарының егәрлеге 60 һәм хәтта 90 метрга кадәр җитә.

Әлеге токым күбесенчә комлы составка ия. Киселешнең аскы өлешендә соры, вак һәм уртача бөртекле, кварц комнары тәкъдим ителә, алар составында бераз гравий-

чуерташ материал да бар. Киселешнең югарырак өлешендә комнарда комлы туфрак, балчыксыл туфрак, ачык көрән һәм яшькелт-көрән төстәге балчылар да барлыкка килә. Днепр аллювие урыны белән 3-5 алып 12-18 метрга кадәр егәрлекле лесска охшаш комлы туфрак һәм балчыксыл туфрак тышчасы белән капланган.

Шилово һәм Мәскәү горизонтларының аллювиаль утырмалары Идел, Казансу һәм Мишә елгаларының су астындагы өченче террасасын тәшкил итә. Террасаның өслеге елга үзәннәре өстеннән 30, ә кайчагында 60 метрга күтәрелеп тора, ә аның барлыкка килгән утырмалары егәрлеге 70-90 метрга җитә. Өслекнең абсолют тамгалары – 70-100 метр, итәгенеке 0+5 метрга тигез.

Терраса нигезендә аллювий комлы-чуерташлы материал буларак билгеләнә, киселешнең өске өлешендә кварцлы, вак бөртекле һәм төрле бөртекле, якты соры һәм соры, балчыклы комнар ята. Су астындагы өченче террасаның өске һәм урта горизонтлары балчык катыш комлы һәм балчыксыл туфраклы катнашмадан тора.

Югары звенога Идел, Казансу һәм Мишә елгасы үзәнлекләрендә су астында торган беренче һәм икенче аллювиаль һәм күл-аллювиаль берәмлекләр керә.

Микулино һәм Калинин офыкларында аллювий утырмалары Идел, Казансу һәм Мишә елгаларының су астындагы өченче террасасын барлыкка китерә. Бу терраса өслегенең абсолют тамгалары – 60-70 метр. Микулино һәм Калинин аллювийларының Идел елгасы үзәнендәге егәрлеге – 20-40 метр, Казансу елгасы үзәнендә – 12-22 метр, Мишә елгасы үзәнендә – 15-20 метр.

Террасаның аскы өлеше – соры һәм саргылт-соры, вак бөртекле, күбесенчә кварцлы комнардан, югары Пермьнең известьташ һәм доломит токымнары чуерташларыннан, өске өлеше соргылт-яшел һәм яшькелт-соры балчык катламнарыннан тора. Югарырак өлештә саргылт-көрән, ачык көрән төстәге балчыксыл туфрак һәм куе һәм саргылт-соры төстәге тузансыман комлы туфрак ята.

Идел, Казансу, Мишә елгаларының тугай өслегендәге беренче террасасында мончалов-осташков горизонты аллювий утырмаларыннан тора. Рельефтагы террасаның өслеге төгәл чагылдырылган, әмма Казан шәһәреннән түбәнрәк өлешендә Куйбышев сусаклагычыннан су баскан. Террасаның аскы өлешендә ачык соры, вак бөртекле, кварцлы комнар ята, өске өлешендә — куе һәм яшькелт-соры балчык һәм туфраклы балчык. Идел үзәнендә тугай өслегенең беренче террасасында аллювий егәрлеге – 22-40 метр.

Столбище кишәрлегендә мончалов-осташков горизонтының күл-аллювий утырмалары зур булмаган үзәнне алып тора, Идел елгасының өченче тугай асты терассасы өслегендә, кайчандыр Ковалев, Архиерей күлләрен һ.б. тоташтырып торган урында урнашканнар. Егәрлеге 1-2-16 метр булган әлеге утырмаларда органик калдыклар күп һәм алар ком, балчык, комлы балчык һәм туфраклы балчыктан гыйбарәт.

Территориядә аллювий һәм күл-аллювий катламнарыннан тыш, башка генезисның неоплейстоцен утырмалары да үсеш алган:

- известьле коңгырт туфрак балчыгыннан торган элювиаль-делювиаль һәм делювиаль утырмалар, алар су бүленгән урыннарда һәм үзәннәрнең сөзәк урыннарында киң таралыш алган.

- эол утырмалары, алар комнан гыйбарәт, су бүленгән урыннарда чикләнгән рәвештә таралыш алган.

Тугай террасасының голоцен аллювий утырмалары зур һәм кечкенә елгаларның үзәнлекләрендә 4 метрдан 0,1 км кадәр киңлектәге полосалар белән үсеш алган. Тугайда, асылда, вак бөртекле кварцлы комнар ята, нигез өлешендә бөртекләренең зурлыклары төрлече, җирлек токымнарга караган вакташ һәм чуерташ белән. Тугайның агым өлешләрендә еш кына тулысынча вакташ һәм карбонат токымнарына караган вакташ катламнары белән капланган балыклар һәм туфраклы балчыклар очрый. Егәрлеге Идел тугаенда 25-30 метр булса, кушылдык өлешләрендә 3-12 метр булып, үзгәреп тора.

Егәрлеге 10-12 метр булган күл-аллювий утырмаларында ком, туфраклы балчык, балчык, органик калдыклары күп булган балчыклар ята.

Юиек террасаларның өслегендә зур булмаган карст уйсулыкларындагы чокырларны тутырып торган биоген (саз) утырмаларында торф, торфланган балчыклар ята, егәрлеге – 1-2 метр.

Куйбышев сусаклагычының Казан шәһәренә тоташа торган сул яры территориясе Идел-Кама артезиан бассейнының көньяк өлешендә урнашкан. Әлеге бассейнның иң характерлы үзенчәлеге – Түбән Пермь яшендәге калын гипслы ангидрит катламының региональ таралышы, ул утырма токымнарының барча ирекле катламнарын кисәк аерылып торган ике гидродинамик зонага бүлә. Гидродинамик активлык дәрәҗәсе буенча кисемнең өстеннән аскы өлешенә таба актив рәвештә су алышына торган һәм су алышыну катлаулы булган зоналар аерылып чыга. Актив су алмашу зонасының аскы чиге шартлы рәвештә Ассель ярусының табан өлешендә кабул ителгән.

Карала торган территориядә су үткәрү төренә һәм зурлыгына, сулы булу характерына карап, түбәндәге гидростратиграфик бүлекчәләр аерып чыгарыла (атамалары, нигездә, Россиянең 1:200000 масштабындагы Дәүләт гидрогеологик картасында гамәлдәге җыелма легенда нигезендә кабул ителгән):

- су үткәрә торган неоген-дүртенчел аллювий комплексы,
- Казанның югары өлешендә су үткәрә торган терриген-карбонат комплексы,
- Казанның аскы өлешендә су үткәрә торган терриген-карбонат комплексы,

Аерып чыгарылган гидростратографик бүлекчәләр актив су алмашына торган зонада урнашкан. Әлеге зонада җир асты агымнарының хәрәкәте райондагы зур елгаларның дренаж йогынтысында тора. Әлеге системаның бердәм җир асты агымы Идел, Казансу, Мишә һәм Кама елгаларына юнәлтелгән. Тагын да тирәнрәк горизонтларда җир асты агымы көнбатышка, көньяк-көнбатышка таба Казан-Кажым борылышына һәм Мәләкәс иңкүлегенә ага.

Карала торган блокта җир асты сулары атмосфера явым-төшемнәре инфильтрациясе хисабына һәм су бүленгән урыннарда һәм зур тугайлыкларның бортларында өске горизонтлардан аскыларына эзлекле рәвештә агып төшә торган сулар хисабына туена. Зур елгаларга караган үзәнлекләрдә этемнәрнең тискәре нисбәте күзәтелә, ул су үткәрә торган аскы Пермь комплексларыннан килгән басым белән аңлатыла.

**Су үткәрә торган неоген-дүртенчел аллювий комплексы**

Өслектән беренче булып яткан су үткәрә торган неоген-дүртенчел комплекс тугайлыкның аллювий утырмаларын һәм Идел елгасы тугае өслегендәге дүрт террасаны, күлләрнең һәм сазлыкларның утырмаларын, шулай ук Идел елгасының борынгы үзәнлекләрендәге плиоцен утырмаларны берләштереп тора. Комплексның су сыйдыра торган токымнары булып төрле зурлыктагы бөртекчәле комнар, вакташ һәм чуерташ кергән, балчык катламнары һәм линзалары күзәтелгән туфраклы балчык тора.

Идел елгасы террасларын тәшкил итүче аллювиаль утырмалар кисемендә фацияләрнең закончалыклы рәвештә алмашынуы күзәтелә: террасалар нигезендә яткан комлы-чуерташ һәм үзәнлек фациясенең ком утырмалары кисемнең өске өлеше буенча, асылда, тугайлык фацияләренең комлы-туфраклы балчык утырмалары белән алмашына.

Су үткәрә торган неоген-дүртенчел комплекс кисеменең аскы өлешләрендә плиоцен яшендәге ком утырмалары ята, алар Идел елгасының борынгы кипкән үзәнлекләрен тутырып тора. Плиоцен комнары кисемендә, астан өскә таба, кипкән үзәнлек кисеме чикләрендә токымнарның алмашынуы күзәтелә. Кипкән үзәнлекләр төбендә эре кисәкле токымнар: вак таш һәм чуерташ утырмалары ком һәм балчык белән тулган. Кисем буенча алга таба өске өлештә аларны чуерташ линзалары белән кварцлы комнар алмаштыра, кисем буйлап өскә таба хәрәкәт иткәндә алар уртача зурлыктагы бөртекчәләргә һәм алга таба ваграк өлешле комнарга күчә. Кисем бортларына таба утырмаларның балчыклы өлешләре арта башлый.

Пермь катламнарының эрозия өслегендә ятып, су үткәрә торган неоген-дүртенчел комплекс палеоз токымнары чыгып торган урыннарда 10 метрдан башлап, эрозия кисемнәре линияләрендә 125-150 метрга кадәр үзгәреп торган егәрлеге белән сыйфатлана.

Комплекстагы күп суның тигезсез күренеше, нигездә, су сыйдыра торган токымнарның егәрлекләре югары дәрәҗәдә үзгәреп торуга бәйле. Скважиналарның чагыштырма дебитлары 0,3 л/с башлап 7,0 л/с кадәр үзгәрә, фильтрация коэффициентлары тәүлегенә 1 метрдан 60 метрга кадәр үзгәреп тора. Неоген-дүртенчел аллювий комплексының җир асты сулары минераллашу дәрәҗәсе башлыча 0,2-0,3 г/дм$^3$ булган гидрокарбонатлы магний-кальцийлы төче сулардан гыйбарәт. Корыган үзәнлекләрнең казылган өлешләре чикләрендә җир асты суларының катылыгы һәм минераллашу дәрәҗәсе акрынлап кына кисем буенча өстән аска таба үзгәрә, аерым урыннарында, кисемнең аскы өлешендә минераллашу дәрәҗәсе 0,6-0,8 г/дм$^3$ җитә һәм катылык дәрәҗәсе – 7-10 ммоль/дм$^3$.

Корыган үзәнлекләрне тутырып торган ком утырмаларының югары фильтрация үзлекләре аларның югары дәрәҗәдә юдыртылып торуын тәэмин итә һәм барлык тирәнлегендә диярлек җир астындагы эчә торган суларны саклый. Сакмар һәм Ассель ярусларының аскы өлешендәге Пермь утырмалары суларының региональ һәм локаль басымы булган өлешләре генә искәрмә булып тора.

Су үткәрә торган неоген-дүртенчел комплекс су бүленгән җирле урыннарда атмосфера явым-төшемнәренең инфильтрациясе хисабына туклана, ә су җирле гидрографик челтәргә һәм Куйбышев сусаклагычына агып төшә. Су үткәрә торган неоген-дүртенчел комплекс су белән тәэмин итү өчен киң кулланыла. Ул су ала торган бер-бер скважинадан вак авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать предприятиеләрен су белән тәэмин итү өчен дә, шулай ук үзәкләштерелгән төркемле су алу корылмаларыннан су белән тәэмин итү өчен дә кулланыла. «Мирный», «Танкодром су алу җайланмалары иң зурлары булып тора. Комплекстан су алуның суммар күләме тәүлегенә якынча 30 мең кв.м$^3$ тәшкил итә. Җир асты суларының сыйфаты норматив таләпләргә туры килми, нигездә, аларның катылыгы югары булуы аркасында.

*Казанның югары өлешендә су үткәрә торган терриген-карбонат комплексы*

Елгалар арасында күмелеп калган борынгы җирләрдә киң таралган су үткәрә торган Казан комплексының өске өлеше 40-45 метр егәрлеккә ия, ә эшләр барган район чикләрендә егәрлекнең калган өлеше – 6-10 метр, терриген-карбонат утырмаларыннан тора: ярыклы мергельләр, комташ, карстланган известьташ һәм доломит. Өслектән беренче булып ул карала торган кишәрлекнең бары тик көнчыгышындагы аерым урыннарында гына ята. Комплексның табан өлешендә кайчак егәрлеге 6-8 метрлы, суны аз үткәрә торган балчыклар ята. Комплекстагы су күләме мәйдан буенча тигезсез урнашкан, скважиналарның чагыштырма дебитлары 0,2 л/с башлап 5,0 л/с арасында үзгәреп тора, су үткәрү дәрәҗәсе тәүлегенә 130 кв.м. башлап 800 м$^2$ кадәр җитә.

Комплексның җир асты сулары дәрәҗәсе, кагыйдә буларак, су үткәрә торган неоген-дүртенчел комплексның грунт сулары дәрәҗәсенә туры килә. Казанның өске өлешендә урнашкан су үткәрә торган терриген-карбонат комплексының төп туклану чыганагы булып Идел елгасының биек террасаларында аллювий комплексы таралган урыннан читтә, өслеккә су чыккан урыннарда елгалар бүленгән киңлектә атмосфера явым-төшемнәренең инфильтрациясе тора, ә су офыгын су үткәрә торган неоген-дүртенчел комплекс утырмалары каплаган урыннарда өстән агып төшкән су хисабына туена.

Югары өлештәге Казан су кертү комплексының җир асты сулары, өйрәнелә торган территориянең күп өлешендә, г/дм$^3$ дәрәҗәсендә минераллаштырылып, гидрокарбонатлы магний-кальцийлы төче сулардан тора. Шуның белән бергә, югары Казандагы җир асты суларының интенсив бушатылган урыннарында түбән Пермьның су китерә торган комплексларында минераллашу дәрәҗәсе 2,4-2,6 г/дм$^3$г/м га кадәр арта. Югары Казан катламнарында минеральләшүнең артуы Куйбышев сусаклагычы яры буенда, шулай ук Мишә һәм Казансу елгалары үзәннәрендә билгеләнә, бу исә тирәнрәк офыкларда җир асты суларының турыдан-туры акмавына бәйле.

Югары Казан терриген-карбонат комплексының җир асты сулары су белән тәэмин итү өчен киң кулланыла. Мәсәлән, Казан шәһәрендә алар хуҗалык-эчә торган су максатларда «Азино» су алу җайланмасы һәм күп кенә берле су алу скважиналарында файдаланыла. Офыктан су алу әйләнешенең гомуми күләме тәүлегенә якынча 36 мең м$^3$.

Бу су алу җайланмаларында җир асты суларының сыйфаты, нигездә, норматив таләпләргә туры килми, иң беренче чиратта, катылыгы югары булу сәбәпле.

*Казанның аскы өлешендә су үткәрә торган терриген-карбонат комплексы*

Комплекс урта Пермьнең түбән Казан подъярсына туры китерелгән. Диңгез фацияләре утырмалары булып тора. Яшьрәк комплекслар астында ята. Анда ул корыган үзәнлекләрдән кала, юылган бөтен җирдә таралган.

Су кертү комплексының өске өлешендәге су сыйдыручы токымнар ярыклы комташ, мергель, известьташ, сирәгрәк вак таш һәм доломит онына кадәр вакланган доломитлар белән уратып алынган. Су кертү комплексының аскы өлешендә егәрлеге 20 метрга кадәр булган участокларда йомшак үтә торган лингула балчыклары пачкасы урнашкан. Комплекс су дәрәҗәсенең югары булуы белән характерлана, скважиналарның чагыштырма дебиты 3,0-6,0 л/с, комплексның су үткәрүчәнлеге тәүлегенә 100 м$^2$ башлап 900 м$^2$ кадәр үзгәрә.

Комплекс асылда су бүлеп чыгара торган офыклардан аккан су хисабына туклана, моннан тыш, түбән Пермь су офыгыннан елга туйгайлыклары буйлап су койган урыннарда агып чыккан су хисабына да тулыланып тора. Бу түбән Казан утырмаларының су үткәрү комплексының күпчелек өлешендә җир асты суларының 0,5-1,0 г/дм$^3$ дәрәҗәсендә минераллаштырылуына китерә, ә елга буйларындагы урыннарда әлеге күрсәткеч 2,3-2,5 г/дм$^3$ кадәр җитә. Шуңа бәйле рәвештә, су бүленгән урыннарда елгаларга булган юнәлешләрдә су үзенең составы буенча гидрокарбонат кальций-магнийлыдан алып сульфатлы- кальцийлы су төренә үзгәрә, сирәкрәк хлорид-сульфатлы суга әверелә, минераллашу дәрәҗәсе – 4,7 г/дм$^3$ кадәр.

Куйбышев сусаклагычының бөтен сул як яры буенча түбән Казанның су үткәрә торган комплексының җир асты сулары ялгыз скважиналар белән бергә зур су алу җайланмалары ярдәмендә дә алына. Эш участогына якын урнашкан скважиналар суны түбән Казанның су үткәрә торган комплексыннан ала. Җир асты суларының сыйфаты чик дәрәҗәдә рөхсәт ителә торган концентратларга туры килә, җир асты суларының минеральләшү дәрәҗәсе – 0,3-0,6 г/дм$^3$, катылыгы — 4,9-7 ммоль/дм$^3$. Түбән Казанның су үткәрә торган комплексының җир асты сулары хуҗалык-эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен киңәш ителергә мөмкин.

## 2. Су алу скважиналарының геологик-техник тасвирламасы

